**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2022 Балык Бистәсе штп. № 353пи

"2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру" муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 8.2 пункты, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. «2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасын (алга таба-Программа) расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетын формалаштырганда, мөмкинлекләрне исәпкә алып һәм бу максатларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган акчалар чикләрендә Программа чараларын гамәлгә ашыруга акча карауны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы предприятиеләренә һәм учреждениеләренә программаның үтәлешен тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "2018-2023 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру" муниципаль программасын раслау турында" 03.10.2018 №234пи карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Л. Исланов